**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында**

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы һәм 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ау параметрларының III кисәгенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6-8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. 2018 елга кадәрге чорга төбәк әһәмиятендәге барлык дәүләт табигать зоология (аучылык) заказникларында һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

7. Татарстан Республикасының барлык аучылык биләмәләрендә 2017 елга кадәрге чорга – ак куянга, суерга, божырга һәм соры көртлеккә, 2016/2017 еллар җәйге-көзге-кышкы ау сезонына һәм 2017 елның язгы ау сезонына – кыр тавыгына һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

8. 2016/2017 еллар ау сезонында «Кама-Исмәгыйль», «Бутино-Чишмә», «Ямаш», «Ласка», «Кайбыч», «Барс», «Арча», «Олы Карагуҗа», «Зеленодольск», «Кызыл Октябрь», «Мизин», «Әтнә», «Үрнәк», «Шуман», «Глухарь», «Охотничьи традиции», «Шора», «Апас», «Буа», «Баиковская Роща», «Фазан», «Югары Ослан», «Свияжск», «Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте), «Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы), «Тәмте» (Югары Ослан районы), «Тәмте» (Кама Тамагы районы), «Алабуга», «Менделеевск»,

«Свиногорье», «Баграж», «Зәй», «Карамалы», «Кызыл-Юл», «Төги», «Охотник», «Идел-Кама», «Никольское», «Камское Раздолье», «Рысь», «Сухарево», «Чишмә», «Ширәмәт», «Дубрава», «Красновидово», «Янтык», «Радуга» аучылык хуҗалыкларыннан һәм Әлмәт, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зеленодольск, Лениногорск, Түбән Кама, Яңа Чишмә районнары ачык аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә соры куянга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.»;

б) 9 пунктның бишенче абзацында «кыр тавыгы һәм төлләтәвечкә» сүзләрен «төлләтәвечкә» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 09 июль
№ ПУ-588